**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 23 декабрь № 982

г. Казань

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарын тотуга аерым чыгымнар формалаштыру нормативларын билгеләү турында

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарын тотуга бюджет акчасын нәтиҗәле сарыф итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлеген төзегәндә кулланыла торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының элемтә хезмәтләре күрсәтү чыгымнары нормативларын бер хезмәткәргә бер елга иң күбе 9,5 мең сум күләмендә; агымдагы башка чыгымнар (коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә, элемтә хезмәтләре күрсәтүгә, мөлкәттән файдаланган өчен аренда түләвенә, ведомствога карамаган сак хезмәтләре күрсәтүгә чыгымнардан тыш) нормативын бер хезмәткәргә аена иң күбе 6,5 мең сум күләмендә дип;

чыгымнарны хисаплап чыгару, максатчан характердагы өстәмә бюджет ассигнованиеләрен исәпкә алмыйча, хезмәткәрләрнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән иң чик санынннан чыгып гамәлгә ашырыла дип.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарын тотуга аерым чыгымнар формалаштыру нормативларын билгеләү турында» 2015 ел, 24 декабрь, 968 нче карары 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип санарга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин